**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422700 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

Тел./факс: +7(84365) 2-35-82, 2-35-85, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**8 февраль 2023 ел** **№ 2**

**Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 23 июнендәге 8 нче номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 23 июнендәге 8 нче номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына 2023 нче елның 16 гыйнварындагы 02-08-23 номерлы Биектау районы прокурорының протестын караганнан соң, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 23 июнендәге 8 нче номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчене кабул иткән вакытта да, шулай ук җаваплы вазыйфаи зат Органга ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) алганнан соң да, гаризаны теркәгән көннән алып 9 эш көненнән артмаган вакытта кабул ителергә мөмкин».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станция поселогы, Совет урамы, 13 йорт адресы буеннча,Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Ф. Нуруллин